Аңа тик тору кыен,
Җылыта ул тәпиен,
Һоп, һоп, һоп, һоп,
Җылыта ул тәпиен.
Куян тик торса – туңа,
Сикергәли ул шуңа,
Һоп, һоп, һоп, һоп,
Сикергәли ул шуңа.

Җырның ахырында куян, ике аякта сикереп, түгәрәк буенча бара һәм берәр баланың алдына килеп туктый. Шул бала «куян» була.

Уенга күрсәтмәләр

• Балалар белән текстны уенга кадәр алдан өйрәнергә кирәк.

• Тәрбияче балаларның сүзләрне дөрес әйтүләрен күзәтә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе “4нче номерлы “Ләйсән” гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы”

***Уйный***

***Үсәбез***

***Уйный***







## Куяным

Тәрбияче балаларны зур түгәрәк ясарга чакыра. Түгәрәк уртасына зур уенчык куян утыртыла.

Тәрбияче җырлый, ә балалар җыр көенә төрле бию хәрәкәтләре ясыйлар, тәрбиячегә кушылып җырлыйлар:

Яшь куянчык шаян була,
Ул уйнарга ярата.
Күрегез, ничек ярата!
Күрегез, ничек ярата!
Я куяным, якын кил!
Матур итеп сикер син.
Менә ничек, менә ничек,
Менә ничек сикер син!
Билләреңә кулың куй,
Матур итеп бие син.
Менә ничек, менә ничек,
Менә ничек бие син!

Уенга күрсәтмәләр

• Уенны уйнаганда, балалар хәрәкәтләрне тәрбияче белән бергә башкаралар.
• Уен өйрәнелеп беткәч, куян ролендә кыюрак бер баланы билгеләргә мөмкин.

## Йонлач көчек

Балалар урындыкларда утырып торалар. Тәрбияче «йонлач көчек» була. Ул бүлмәнең бер читендә алгасузылган кулларына башын куеп утыра – «йоклый».Балалар, түбәндәге текстны әйтә-әйтә, әкрен генә аның янына киләләр:

Әнә ята йонлач көчек,
Борынын сузган ул ничек?
Йоклаганга да ошый,
Әллә юриме мышный?
Уятыйк үзен – торсын!
Нәрсә булса да булсын!

Балалар, шигырьне әйтеп бетергәннән соң, көчекне сыйпыйлар, иркәлиләр. Кинәт көчек күзен ача, сикерә, өрә башлый. Балалар урыннарына таба йөгерәләр, көчек аларны куа.

Тотылган баланы «көчек» итеп билгеләргә мөмкин.

Уенга күрсәтмәләр

• Шигырьне әйтеп бетерми торып, балалар көчеккә кагылмыйлар.
• Балалар көчекне бераз сыйпаганнан соң гына, ул күзләрен ача, селкенә башлый.
• Уенны үзләштергәннән соң, көчекне балалар арасыннан сайларга мөмкин.
• Шигырьне алдан өйрәнергә кирәк.

## Куян

Балалар түгәрәкләнеп басып торалар. Бер бала «куян» итеп билгеләнә. Ул түгәрәкнең уртасында тора. Барлык балалар тәрбияче белән бергә җырлыйлар һәм җырның эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар:

Ап-ак куян утыра,
Колагын селкеп тора,
Менә шулай, менә шулай
Колагын селкеп тора.